**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы**
**Кәрәкәшле авыл җирлеге Советы**

КАРАР № 11

Кәрәкәшле ав. 6 нчы июль 2022 ел

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Советының 2021 елның 25 ноябрендәге 15 санлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» Кәрәкәшле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Конституциясе, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2020 елның 31 июлендәге «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында»гы 248-ФЗ санлы Федераль закон, 2008 елның 26 декабрендәге «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында»гы 294-ФЗ санлы Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Кәрәкәшле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең 2019 елның 17 июлендәге 10 санлы карары белән кабул ителгән Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Советы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Кәрәкәшле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең норматив хокукый актларын гамәлдәге законнарга туры китерүгә бәйле рәвештә, Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Советының 2021 елның 25 ноябрендәге 15 санлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» Кәрәкәшле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. “Гомуми нигезләмәләр» 1.3 пунктының 1 маддәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль Кәрәкәшле авыл җирлеге башкарма комитеты (алга таба - вәкаләтле орган) тарафыннан башкарыла.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Кәрәкәшле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча урнаштырырга:

http://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталын «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru.

3. Әлеге карар рәсми халыкка игълан ителгәннән бирле үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен үз контролемдә тотам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгы: А.Г.Давлетгареев